| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КРАСНОБОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КРАСНЫЙ БОР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.04.2021 Красный Бор авылы № 6

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге территориясендә махсус янгынга каршы режим кертү турында

Язгы-җәйге чорда янгын куркынычы дәрәҗәсе артуга бәйле рәвештә, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы, «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» 2021 елның 23 апрелендәге 280 номерлы карарын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге территориясендә 2021 елның 26 апреленнән 2021 елның 16 маена кадәр янгынга каршы режим кертергә.

2. Расларга:

- табигый янгыннар һәм яна торган җирләр табылган урыннарда эш алып баруны тәэмин итү һәм халык арасында профилактик эш башкару буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлегенең патруль төркеме (1 нче кушымта);

- табигый янгыннар һәм яна торган җирләр табылган урыннарда эш алып баруны тәэмин итү һәм халык арасында профилактик эш башкару буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегенең патруль-контроль төркеме графигы һәм маршрутлары (2 нче кушымта).

3. Патруль-контроль төркеменең эш нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының ЕДДС хезмәтенә хәбәр итәргә.

4. Красный Бор выл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда физик, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга тыярга:

учаклар кабызу, каты көнкүреш калдыкларын, коры үләннәрне һәм чүп-чарны яндыру;

мангаллардан һәм башка җайланмалардан тыш җәмәгать туклануы объектлары (рестораннар, кафе, барлар һ. б.), гражданнар карамагындагы торак пунктларда (алга таба - бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте), урман янгыннары куркынычы янаган икътисад объектлары территорияләрендә урнашкан махсус янып бетмәгән савытларда, ризыкны җылылык белән эшкәртү өчен башка җайланмаларда азык әзерләү өчен ачык ут куллану;

торак пунктлар территорияләрендә, балаларның ялын һәм аларны савыктыру оешмаларында, бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтләрендә, икътисад объектларында, сәламәтләндерү оешмаларында, шулай ук урман-парк зоналарында, урман массивлары белән чиктәш торф участокларында һәм ачык территорияләрдә урман янгыннарына янауга бәйле рәвештә 1-3 класслы куркыныч тудыручы пиротехник эшләнмәләр куллану;

күтәрү принцибы ачык ут ярдәмендә конструкцияләр эчендәге һаваны җылытуга нигезләнгән яна торган материаллардан идарә ителми торган эшләнмәләрне очыру.

5. Учреждениеләр, оешмалар, предприятиеләр җитәкчеләренә (мөлкәти һәм оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга тәкъдим итәргә:

ведомство буйсынуындагы объектларның территорияләрен коры үләннән һәм чүп-чардан чистарту чараларын күрергә;

баланста булган тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының эшкә яраклылыгын тикшерергә;

янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычы булган эшләр башкаруны чикләргә.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге территориясендә:

урман янгыннарына куркыныч янаган торак пунктларда вакытлыча янгын сүндерү постлары булдырырга;

коры үләнле үсемлекләр януын ачыклау, шулай ук янгын учаклары табылган очракларда оператив эш итү максатында һәр торак пунктта патруль-контроль группалары булдырырга һәм аларның эшен оештырырга, янгын куркынычы янаган чор башланганчы Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына тапшырырга тиешле әлеге төркемнәрнең эш графикларын эшләргә;

торак пунктлар, бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре территорияләрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү һәм янгын куркынычы барлыкка килгәндә гамәлләр тәртибе буенча халык белән аңлату эшләре алып барырга һәм аларны планлаштырырга, әлеге юнәлештә массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлекне оештырырга;

янгын куркынычы сезоны башланганчы, торак пунктларны һәм икътисад объектларын табигый (урман) янгыннардан саклау өчен минераллаштырылган полосалар булдыру, территорияләрне коры үлән үсемлекләреннән, ауган агачлардан, чүп-чардан һәм башка янучан материаллардан чистарту эшләрен, бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтләре территорияләрендә хуҗасыз һәм озак вакыт файдаланылмый торган җир кишәрлекләре төзүне төгәлләргә;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләре утырышларында торак пунктларның янгын куркынычсызлыгы торышы турындагы мәсьәләләрне карарга;

табигый һәм ясалма су чыганакларын һәм янгын сүндерү машиналары белән су алу юлларын төзек хәлдә булуын тәэмин итәргә;

табигый янгыннарны сүндерүгә карата гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль өстәмә системасының муниципаль звенолары көчләренең һәм чараларының әзерлеген тикшерергә;

урман янгыннары торышын катлауландыру чорына ирекле һәм муниципаль янгын сагы әгъзаларының тәүлек буе кизү тору планнарын, шулай ук су сиптерү һәм техниканы янгын сүндерү өчен җайлаштырылган башка техниканы җәлеп итү планнарын төзергә;

табигый янгыннарга бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү, торак пунктларны, икътисад һәм социаль инфраструктура объектларын урман янгыннарыннан яклау, шулай ук урман янгыннарын сүндерү өчен билгеләнгән көчләрне һәм чараларны муниципальара маневрлау буенча комплекслы өйрәнүләр үткәрергә;

табигать янгыннары барлыкка килгән очракта халыкка хәбәр итү һәм эвакуацияләү мәсьәләләрен хәл итәргә;

кешеләрне вакытлыча урнаштыру пунктларының янгын куркынычы чорына эшкә әзерлеген тикшерергә;

эвакуацияләнгән халыкны беренче чиратта яшәтү планнарын эшләү;

кешеләргә янгын турында хәбәр итү чараларының тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итәргә;

«Югары әзерлек» һәм (яисә) «Гадәттән тыш хәл» режимнарының табигый янгыннар барлыкка килү һәм килеп чыгу куркынычы булганда үз вакытында кертелүен тәэмин итәргә;

7. Балансында балалар ялын оештыру һәм аларны савыктыруны оештыру булган һәм урман янгыннары куркынычы янаган оешмалар җитәкчеләренә:

оешмаларның вазыйфаи затлары арасыннан янгынны вакытында ачыклау өчен патруль төркемнәре төзергә;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы ведомствосындагы учреждениесе янгын чыгу турында хәбәр итү тәртибен эшләргә;

табигать (урман) янгыны барлыкка килгән очракта, балаларга хәбәр итү һәм оешма территориясеннән эвакуацияләү тәртибен эшләргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында - http://agryz.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

9. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе А.Н. Лазарев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Красный Бор авыл җирлеге
башкарма комитеты
карарына 1 нче кушымта

**Табигый янгыннар һәм яна торган җирләр табылган урыннарда эш алып баруны тәэмин итү һәм халык арасында профилактик эш башкару буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлегенең патруль төркеме**

| № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Патруль-контроль төркемендә вазыйфасы, статусы | Контакт телефоннар | Маршрут номеры |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Ефремов Алексей Владимирович | Красный Бор авылының ОП МЧС башлыгы | 8(85551)3-91-01 | 1 |
| 2. | Гараев Риназ Альбертович | Красный Бор авылының ОП МЧС бүлек командиры | 8(85551)3-91-01 | 2 |
| 3. | Глухов Александр Владимирович | Красный Бор авылының ДПОсы | 89600663298 | 3 |
| 4. | Баранов Сергей Владимирович | Красный Бор авылының ДПОсы | 89093117905 | 4 |

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Красный Бор авыл җирлеге
башкарма комитеты
карарына 2 нче кушымта

**Табигый янгыннар һәм яна торган җирләр табылган урыннарда эш алып баруны тәэмин итү һәм халык арасында профилактик эш башкару буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегенең патруль-контроль төркеме графигы һәм маршрутлары**

| Маршрут номеры | Авыл җирлегенең торак пункты исеме | Урам исеме | Патруль-контроль төркеменең эш графигы |
|---|---|---|---|
| 1 | Красный Бор авылы | Көнчыгыш ур.<br>Красный бор ур.<br>Яңа ур.,<br>Марс тавы,ур. | 2021 елның 26 апрель - 16 нчы май көннәре |
| 2 | Красный Бор авылы | Гагарин ур.,<br>Яр буе ур.<br>Хезмәт ур.,<br>Спорт ур.<br>Яшьлек ур. | 2021 елның 26 апрель - 16 нчы май көннәре |
| 3 | Красный Бор авылы | Төзүчеләр ур.<br>Елга арты ур.<br>Совхоз ур.<br>Толстой ур.<br>Октябрь ур. | 2021 елның 26 апрель - 16 нчы май көннәре |
| 4 | Красный Бор авылы | Сельхозтехника ур.,<br>Яшьләр ур.<br>Горький ур.<br>Маркин ур. | 2021 елның 26 апрель - 16 нчы май көннәре |